| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

05.12.2019 — № 1667-п

Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә 2019 елда үсемлекләрне химик саклау буенча сатып алынган әйберләргә һәм үсеш стимуляторларына тотылган чыгымнарны каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Авыл хуҗалыгы культураларының уңдырышлылыгын һәм сыйфатын арттыру максатыннан, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә 2019 елда үсемлекләрне химик саклау буенча сатып алынган әйберләргә һәм үсеш стимуляторларына тотылган чыгымнарны каплауга субсидияләр бирү тәртибен расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән субсидияләрне бирү максатларында, Саба муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына (алга таба – ФБП), Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының https://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында субсидия бирү турында хәбәрнамә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы,
инвестицион үсеш һәм эшкуарлыкка ярдәм итү буенча
Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары - Саба
муниципаль районының инвестицион үсеш һәм
эшкуарлыкка ярдәм итү бүлеге башлыгы И. И. Котдусов

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Башкарма комитетының
____________________
____________________
номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

**Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә 2019 елда үсемлекләрне химик саклау буенча сатып алынган әйберләргә һәм үсеш стимуляторларына тотылган чыгымнарны каплауга субсидияләр бирү тәртибе**

**1. Субсидияләр бирү турында гомуми нигезләмәләр**

**1.1.** Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә 2019 елда үсемлекләрне химик саклау буенча сатып алынган әйберләргә һәм үсеш стимуляторларына тотылган чыгымнарны каплауга субсидияләр бирүнең әлеге тәртибе, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә 2019 елда үсемлекләрне химик саклау буенча сатып алынган әйберләргә һәм үсеш стимуляторларына тотылган чыгымнарны каплау өчен җирле бюджет акчалары хисабына субсидияләр бирү процедурасын билгели.

**1.2.** Барлык милек рәвешләрендәге авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләренә (алга таба – авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләре) субсидияләр бирүнең максаты-2019 елда үсемлекләрне химик саклау буенча сатып алынган әйберләргә һәм үсеш стимуляторларына тотылган чыгымнарны каплау һәм авыл хуҗалыгы культураларының уңдырышлылыгын һәм сыйфатын арттыру.

**1.3.** Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җирле үзидарә органы булып тора, аңа, Россия Федерациясе Бюджет законнары нигезендә, бюджет акчаларын алучы буларак, билгеләнгән тәртиптә 2019 финанс елына субсидияләр бирү буенча бюджет йөкләмәләренең лимитлары җиткерелгән (алга таба – бюджет акчаларын алучы буларак җаваплы оештыручы).

**1.4.** Субсидия бирү Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының 2019 елга һәм 2020, 2021 елларның планлы чорына бюджеты турында”гы 2018 елның 19 декабрендә кабул ителгән 272 номерлы карарында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә әлеге тәртипнең 1.2. пунктында күрсәтелгән максатларга гамәлгә ашырыла.

**1.5.** Субсидия бирү турында белдерү субсидия бирү турында гаризалар кабул итү тәмамланганчыга кадәр кимендә унбиш көн кала Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырыла.

**1.6.** 2019 елда үсемлекләрне химик саклау буенча сатып алынган әйберләргә һәм үсеш стимуляторларына тотылган чыгымнарны каплауга субсидияләр (алга таба – субсидияләр) Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә авыл хуҗалыгы культураларының чәчү мәйданнары булган үсемлекчелек продукциясен җитештерү һәм сату белән шөгыльләнүче авыл хуҗалыгы оешмаларына, крестьян (фермер) хуҗалыкларына бирелә.

**1.7.** Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләренә субсидияләр, НДС һәм транспорт чыгымнарын исәпкә алмыйча, 2019 елда сатып алынган үсемлекләрне саклаучы химик әйберләр һәм үсеш стимуляторлары бәясенең 100% күләмендә бирелә.

**1.8.** Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең исәп-хисап счетларына Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Саба районы буенча Казначылык Департаментының территориаль бүлегендә ачылган шәхси счетыннан субсидияләр күчерүне гамәлгә ашыра.

## 2. Субсидияләр бирү шартлары һәм тәртибе.

**2.1**. Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре субсидия алу өчен Саба муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына (алга таба - ФБП) түбәндәге документларны тапшыралар:

– юридик затны (шәхси эшкуарның) дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе;

– Уставның күчермәсе (юридик затлар өчен) һәм аның оригиналы, шулай ук (булган очракта) аңа кертелгән барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр (күзәтү өчен оригинал);

– Затны булдыру турында вәкаләтле органның гамәлгә кую килешүе яки карарының күчермәсе һәм аның оригиналы (күзәтү өчен оригинал);

– салым исәбенә куелу турында таныклык күчермәсе;

– бурычка алучы исеменнән гамәлләр башкаруга затның вәкаләтләрен раслый торган документ;

– 2019 елда үсемлекләрне химик саклау әйберләре һәм үсеш стимуляторлары белән тәэмин итү килешүе;

– 2019 елда үсемлекләрне химик саклау әйберләрен һәм үсеш стимуляторларын кертү буенча хезмәтләр күрсәтүгә килешү;

– “2019 ел уңышы өчен чәчү йомгаклары турында мәгълүматлар” №4-СХ яки № 1-фермер формалары буенча хисаплар (алга таба-статистик хисаплар);

– түләү фактын раслаучы счет-фактуралар, товар-транспорт накладнойлары, түләү йөкләмәләре, башкарылган эшләр актлары;

– үзара йөкләмәләрне исәпкә алу турында килешүләр;

– 2019 елда үсемлекләрне химик саклау һәм үсеш стимуляторлары буенча чыгымнарны каплауга исәп-хисап;

– авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләре тарафыннан 2019 елда үсемлекләрне химик саклау һәм үсеш стимуляторлары буенча тотылган чыгымнарны каплауга Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетыннан акча алынмавы турында белешмә.

**2.2.** ФБП шушы Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документларның дөреслеген тикшерә һәм Саба муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр алу өчен гаризаларны карау һәм бәяләү буенча комиссиягә субсидияләр бирү һәм Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2013 елның 19 мартындагы 303-п номерлы карары белән расланган җиңүчеләрне билгеләү турында мәсьәләне карау өчен (алга таба - Комиссия) авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең беркетелгән документлары белән гаризаларын тәкъдим итә.

**2.3.** Документлар һәм материаллар кергәннән соң, Комиссия аларны карый һәм субсидия бирү мөмкинлеге турында карар чыгара яисә, сәбәпләрен күрсәтеп, субсидия бирүдән баш тарта.

**2.4**. Бурычка алучыга субсидияләр бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

– Бурычка алучы тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 2.1, 2.6 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яисә күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

– Субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмавы.

**2.5.** Комиссия уңай карар кабул иткән очракта, Башкарма комитет субсидия бирү турында килешү төзи һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментының Саба районы буенча территориаль бүлегендә ачылган үзенең шәхси счетыннан авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләрнең исәп-хисап счетларына субсидия күчерүне гамәлгә ашыра**.**

Субсидия бирү турындагы килешү 1 елга гамәлдә булу срогы белән төзелә.

**2.6**. Субсидия бирү турында карар кабул итү планлаштырыла торган айның беренче числосына субсидия алуга дәгъва итүчеләрнең:

– салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычлары булырга тиеш түгел;

– Саба муниципаль районы бюджетына субсидияләр, шул исәптән башка хокукый актларга туры китереп бирелгән бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча һәм шушы карар нигезендә субсидияләр бирү планлаштырылган Саба муниципаль районы бюджеты алдында билгеләнгән башка бурычны кире кайтару буенча срогы чыккан бурычлары булырга тиеш түгел;

– әгәр алар юридик затлар булып торсалар, үзгәртеп кору, юкка чыгу, банкротлык процессында булырга тиеш түгел, ә субсидияләр алучылар - шәхси эшмәкәрләр шәхси эшкуар буларак эшчәнлеген туктатырга тиеш түгел яисә аларның эшчәнлеге тукталган булырга тиеш түгел (әгәр мондый таләп хокукый акт белән каралган булса);

– чит ил юридик затлары, шулай ук устав (җыелма) капиталында теркәлү урыны булып Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган Салым салуның ташламалы салым режимын бирә торган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән дәүләт яисә территория булган чит ил юридик затларының катнашу өлеше торган Россия юридик затлары булырга тиеш түгел;

– әлеге хокукый акт һәм бюджет турындагы карар нигезендә әлеге карарның 1.2 пунктында күрсәтелгән максатларга башка норматив хокукый актлар яисә муниципаль хокукый актлар нигезендә субсидия бирү планлаштырылган Саба муниципаль районы бюджетыннан акчалар алырга тиеш түгел;

– хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү буенча бурычлары булырга тиеш түгел;

– бюджет кредитлары буенча бурычлары булырга тиеш түгел.

**2.7.** Субсидияләр Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2013 елның 22 июлендәге 1001-п номерлы карары белән расланган Административ регламентта билгеләнгән срокларда, әмма ул документларны карау нәтиҗәләре буенча җаваплы оештыручы белән килешү төзегәннән соң унынчы эш көненнән дә соңга калмыйча күчерелә.

## 3. Хисапка таләпләр.

**3.1.** Күрсәткечләргә ирешү турындагы хисапка таләпләр, аерым алганда, күрсәткечләргә ирешү турында субсидия алучы тарафыннан хисап тапшыру тәртибен, срокларын һәм формасын ачыклау билгеләнми.

## 4. Субсидияләр бирү шартларының, максатларының һәм тәртибенең үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру турындагы таләпләр һәм аларны бозган өчен җаваплылык.

**4.1.** Бюджет акчаларының максатчан кулланылышын, бюджет акчаларын алучы буларак, Саба муниципаль районының Контроль-хисап палатасы һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты контрольдә тота.

**4.2.** Саба муниципаль районының Контроль-хисап палатасы һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерәләр.

**4.3.** Бирелгән субсидия, бюджет акчаларын алучы һәм муниципаль финанс контроленең вәкаләтле органы булып торган җаваплы оештыручы һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Контроль-хисап палатасы үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган, субсидия алучы тарафыннан субсидияләр биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган очракта, кире кайтарылырга тиеш.

**4.4.** Бирелгән субсидияләр, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджеты керемендә, субсидияләр алу өчен дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшыру фактларын ачыклау буенча Башкарма комитетның тиешле таләбен алган көннән алып 60 көн эчендә кайтарылырга тиеш.

**4.5**. Әлеге акчаларны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджеты керемендә ирекле рәвештә кире кайтарудан баш тарткан очракта, алар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә мәҗбүри рәвештә түләттерелергә тиеш.

**4.6.** Бирелә торган документларның дөреслеге, бюджет акчаларын максатчан һәм нәтиҗәле файдалану, коррупциягә каршы законнарны үтәү өчен җаваплылык субсидия алучыларга йөкләнә. Закон бозучыларга карата гамәлдәге законнарда каралган җаваплылык чаралары кулланыла.